БАЛТАСИН РАЙОНЫЙ
ИСПОЛНИК КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЛАР

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

"10" 04 2023 ел № 140

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «”Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының үрнәк формасын раслау хакында» 2023 елның 13 сентябрендәге 33/23 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2021 елның 17 июнендәге 190 номерлы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасарына һәм «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ начальнигына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов